# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль район Кәүҗияк авыл җирлеге Түбән Бикмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2024 елның 1 ноябре** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «2024 елның 1ноябрендә узган гражданнар җыенының "сез 2025 елда һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча үткәрелгән йомгаклау беркетмәсе төзелде., Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Түбән Бикмәт территориясендә теркәлгән, моннан тыш, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү өчен үзарасалым кертергә килешәсезме:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Бикмәт торак пункты территориясендә агачларны кисү (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Түбән Бикмәт торак пункты территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча туплау урыннарын җыештыру (махсус техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 33 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 22 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: җыенда катнашкан 22 кеше «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Түбән Бикмәт торак пунктында гражданнар җыенын уздырылган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен- дөрес дип таныргa.

2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Түбән Бикмәт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә,

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү " мәсьәләсе буенча карар кабул итәргә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Бикмәт торак пункты территориясендә агачларны кисү (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Түбән Бикмәт торак пункты территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча туплау урыннарын җыештыру (махсус техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнарга игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф. Ә. Хөснетдинов